**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА-СЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЕШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**423741, Аеш авылы,**
**Ленин ур.,34б нче йорт.**
**Тел/факс 3-44-41**
**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

**СОВЕТ АИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423741, село Аишево, ул.Ленина, дом 34б.**
**Тел/факс 3-44-41**
**e–mail: aish-akt.galeeva@yandex.ru**

РЕШЕНИЕ КАРАР

23 март 2026 ел №6

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 14.12.2023 ел №19 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 ел, № 425-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аеш авыл җирлеге Советы «Җир салымы турында» 14.12. 2023 ел 19 номерлы карарына (19.12.2023 № 21, 03.04.2024 № 2, 07.11.2024 № 19, 22.10.2025 № 6 кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр әлеге пунктта башкасы каралмаган булса, салымны салым түләүче-оешмалар узган салым чорыннан соң киләгә торган елның 28 мартыннан да соңга калмыйча түләргә тиеш, салым буенча аванс түләүләре узган хисап чорыннан соң килә торган икенче айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча салым түләүче-оешмалар тарафыннан түләнергә тиеш.»;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«Узган салым (хисап) чорлары өчен салым (салым буенча аванс түләве) суммасын исәпләүгә (яңадан исәпләүгә) китерә торган белешмәләр нигезендә исәпләнгән салым (салым буенча аванс түләве) салым түләүчеләр-оешмалар тарафыннан исәпләнгән салым (салым буенча аванс түләве) турында хәбәр төзелгән айдан соң килә торган айның 28 нче числосыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш.салым органы тарафыннан тиешле чор өчен салым (салым буенча аванс түләве) суммасына (әлеге статьяда алга таба-исәпләнгән салым суммасы турында хәбәр).»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Актаныш муниципаль районы Аеш
авыл җирлеге Советы Рәисе Д.Р.Әхәтов